**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 елның «29» мартыннан № 21

**«Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының 2011 елның 28 февралендәге 10 номерлы карары белән расланган Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе кодексына үзгәрешләр кертү турында»**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе кодексына үзгәреш кертү турында» 2014 елның 29 ноябрендәге ПУ-1100 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, карар бирәм:

1. Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибенә үзгәрешләр кертергә:

- Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең этика Кодексының 3 п.п. пунктында «хезмәт эшчәнлеге барышында» сүзләрен «үз хезмәт эшчәнлеген башкарганда, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә (бастырып чыгарырга).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль**
**районы Башлыгы** **В.М. Козлов**